СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

09.06.2025 № 7/вн-1

На №__________от______________

# КАРАР

**Җирлекләрнең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы 4 пункты, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй, Боерган, Борды, Калмаш, Калмия, Князево, Комсомолец, Күзкәй, Кече Шилнә, Мусабай-Завод, Түбән Суыксу, Яңа Троицкий, Сәмәкәй, Иске Абдул, Иске Дөреш, Теләнче-Тамак, Шилнәбаш, Яңа Бүләк авыл җирлеге вәкиллекле органнарының күрсәтелгән җирлекләрнең түбәндәге вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында тәкъдимен кабул итәргә:

- авыл җирлеге милеге хокукын туктатуны (читләштерүне) таләп итмәүче күчемсез мөлкәт белән эш итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру.

2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына:

- Тукай муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетлары белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә.

3. Әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Тукай муниципаль районының мәгълүмат сайтында (https://tukay.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазифаларын башкаручы,
Совет Рәисе урынбасары

Совет ТУКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА ОГРН 1051667007039 ИНН 1639031685

Р.И. Закиров